# ДОГОВОР
## о сотрудничестве учреждения дополнительного образования детей с учреждением общего образования

20. 09. 2017 г.

Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования «Центр внешкольной работы» Московского района г. Казани (далее ЦВР) в лице директора Р.М.Богомоловой и Муниципальное бюджетное образовательное учреждение «Татарская гимназия № 17 им.Г. Ибрагимова Московского района г. Казани (далее – Школа) в лице директора А.А.Галиевой, заключили настоящий договор о сотрудничестве и творческих контактах.

Настоящий Договор определяет взаимоотношения между образовательным учреждением в области обучения и воспитания детей в сфере дополнительного образования.

Стороны Договора осуществляют двустороннее сотрудничество с целью:
- взаимного содействия приобщения обучающихся к миру прекрасного: танцам, изобразительному искусству, театральному миру, а также воспитание усидчивости и творческих способностей.

### 1. Обязанности сторон

1.1. МБУДО «ЦВР» обязуется:

- использовать имущество, находящееся в помещении № 18 гимназии № 17: комплект ученической мебели – 15 шт., доска -1 шт., шкаф – 1 шт., согласно договора безвозмездного пользования муниципальным имуществом г. Казани № 3/173 от 22. 07.2017 г. строго по назначению.
- обеспечивать образовательный процесс квалифицированными педагогами.

1.2. МБОУ «Гимназия № 17» обязуется:

- предоставлять имущество, согласно договора безвозмездного пользования муниципальным имуществом г. Казани № 3/173 от 22.07.2017 г., необходимое для ведения образовательного процесса во внеурочное время: комплект ученической мебели – 15 шт., доска -1 шт., шкаф – 1 шт.

### 2. Срок действия договора

2.1. Договор заключается на неопределённый срок и вступает в силу с момента его заключения.
2.2. Настоящий договор вступает в силу с момента его подписания сторонами.
2.3. Настоящий договор может быть расторгнут в одностороннем порядке. При этом сторона, желающая расторгнуть договор, должна сообщить о своих намерениях другой стороне не менее, чем за две недели до его расторжения.

### 3. Прочие условия

3.1. Настоящий договор не предусматривает взаимных расчетов сторон.
3.2. Все изменения, дополнения к договору действительны только в том случае, если они составлены в письменной форме и подписаны обеими сторонами.
3.3. Договор составлен в двух подлинных экземплярах, по одному для каждой из сторон.

### 4. Юридические адреса сторон

| | |
|---|---|
| МБУДО «Центр внешкольной работы» | МБОУ «Гимназия № 17 им. Г. Ибрагимова |
| Московского района г. Казани | Московского района г. Казани |
| Адрес: ул. Восстания, д.61А | Адрес: ул. Восстания, д.48 |
| Телефон: (843) 557-40-56 | Телефон: (843) 564-31-51 |
| **Директор** ____________ **Р.М.Богомолова** | **Директор** ____________ **А.А.Галиева** |
| м.п. | м.п |

**ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ ПО КИРОВСКОМУ И МОСКОВСКОМУ РАЙОНАМ УПРАВЛЕНИЯ ОБРАЗОВАНИЯ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОДА КАЗАНИ**
**МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЦЕНТР ВНЕШКОЛЬНОЙ РАБОТЫ» МОСКОВСКОГО РАЙОНА ГОРОДА КАЗАНИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

| | | |
|---|---|---|
| Принята на заседании педагогического совета<br><br>Протокол № 1<br>от «31» августа 2022 года | «Согласовано»<br>Директор МБОУ «Татарская гимназия №17 им.Г.Ибрагимова»<br><br>___________А.А. Галиева | «Утверждаю»:<br>Директор МБУДО ЦВР<br><br>___________Р.М.Богомолова<br>Приказ № 180<br>от «31» августа 2022 года |

# ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА
# “Илhам”

***Направленность:*** художественная
***Возраст учащихся:*** 10-12 лет
***Срок реализации:***2 года

***Автор-составитель:***
Самигуллина Ляйсан Фиргатовна,
педагог дополнительного образования

**Казань 2021**

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

“Илһам” әдәби - иҗат берләшмәсе укучыларда иҗат итү теләге булдыру, иҗади сәләтне, сөйләм һәм язма телне үстерү максаты белән оештырыла.

Для создания наиболее благоприятных условий реализации дополнительной общеобразовательной общеразвивающей программы МБУДО «Центр внешкольной работы» Московского района города Казани заключил договор о сетевом взаимодействии с МБОУ « Татарская гимназия №17 им.Г.Ибрагимова». Предусмотрено проведение совместных мероприятий с использованием помещений и оборудования.

**Программаны эшләүдә кулланылган төп норматив документлар:**

Содержание программы разработано в соответствии с Законом об Образовании №273-ФЗ от 29.12.2012 г., Приказом Министерства просвещения РФ от 09.11.2018 №196 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам»; паспортом национального проекта «Образование»; СанПиН 3.1/2.4.3598-20; Письмом Министерства образования и науки Республики Татарстан от 04.04.2020 № 4123/20 «О направлении методических рекомендаций по организации электронного обучения с применением дистанционных образовательных технологий в образовательных организациях, реализующих дополнительные общеобразовательные программы».; Концепцией развития дополнительного образования детей до 2030 года (ред.31.03.2022), Приказом МО и Н РТ №1465/14 от 20.03.2014г «Об утверждении Модельного стандарта качества муниципальной услуги по организации предоставления дополнительного образования детей в многопрофильных организациях дополнительного образования в новой редакции"; Планом мероприятий по реализации в 2021-2025 годах «Стратегии развития воспитания в Российской Федерации на период до 2025 года» утверждённом Распоряжением Правительства Российской Федерации от 12.11.2020 г. № 2945-р, Уставом МБУДО "ЦВР" Московского района г.Казани.

“Илһам” әдәби-иҗат берләшмәсе **дәрестән тыш эшчәнлекнең бер юнәлеше** буларак тәкъдим ителә. Программа эчтәлеге һәм укыту методлары буенча укучыларның дәресләрдә алган белем-күнекмәләрен тулыландыру, укуга кызыксыну тәрбияләү, укыту һәм тәрбиянең бергәлеген ныгытуда зур роль уйный. Балаларның яшьтән үк татар халык иҗатын, татар әдәбиятын, гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнүе дә игътибарга лаек. Шул ук вакытта балаларның сөйләм телен үстерү дә мөһим бурычларның берсе булып тора.

Белем һәм тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеге балаларда укуга кызыксындыру уятуга бәйле. Укытуның төп формасы – дәрес. Ләкин дәрес кысаларында гына телнең

матурлыгын, байлыгын, тирәнлеген күрсәтү өчен мөмкинлекләр чикләнгән. Чөнки, беренчедән, әдәбият дәресләренә, бигрәк тә урта һәм югары мәктәптә, бик аз сәгатьләр бирелә. Икенчедән, программа материалыннан тыш та хәзинәгә тиңләрлек әсәрләребез бик күп, аларның барысын да мәктәп программасына кертеп бетерү мөмкин түгел. "Илһам" әдәби-иҗат берләшмәсе программасының **актуальлеге** шулар белән аңлатыла.

Түгәрәктә

- әдәбият теориясе, журналистика жанрлары, татар әдәбияты һәм аның тарихы буенча мәгълүмат биреләчәк;

- шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр язып карау, фәнни-эзләнү эше башкару күздә тотылачак.

- татар теле кабинетында балалар шагыйре Шәүкәт Галиевның музей почмагын булдыру эше алып барылачак (материал туплау, экспонатлар булдыру, стендлар эшләү, экскурсоводлар булдыру һ.б.)

Программа өчен материал туплаганда, иң элек әсәрнең баланы ни дәрәҗәдә кызыксындыра алуы (үзенең эчтәлеге белән балага якын булуы), сөйләм телен баетуга ярдәме, тәрбияви әһәмияте искә алынды. Шулай ук балаларның психологик үсеше һәм яшь үзенчәлекләренә зур игътибар бирелде.

**Максат:** укучыларда татар теленең күп мәдәниятле мохиттәге роле һәм әһәмияте турында беренчел күзаллау формалаштыру; аларда татар халык иҗатына, мәдәниятенә, матбугатына һәм әдәбиятына ихтирам хисе тәрбияләү, ватанпәрвәрлек хисе уяту, иҗади сәләтләрен арттыру.

**Программаның бурычлары**

**Белем бирү бурычы:**

- укучыларда татарча укуга кызыксыну, омтылыш уяту;
- укучыларның иҗади шәхес буларак формалашуына булышу;
- әдәби әсәрләрне дөрес, йөгерек, аңлап, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру,
- текстны аңларга, аңлаганны тыңлаучыга җиткерергә, дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, тема буенча әңгәмә кора белергә, аралашканда тел чараларын урынлы файдалана белергә өйрәтү;
- әсәрнең тел-бизәкләү, сурәтләү чараларын табу, анализлау күнекмәләрен үстерү; темасын һәм төп геройның характерын, эш-гамәлләрен, әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен белдерергә өйрәтү;
- милли матбугат белән кызыксындыру, укучыларга матбугат жанрлары, төрләре буенча башлангыч белем бирү;

**Белем һәм күнекмәләрне камилләштерү бурычы:**

- Укучыларның иҗади сәләтләрен төрле яклап үстерү, гомуми күзаллауларын киңәйтү.

- Әдәби иҗатка, матбугатка кагылышлы теоретик белемнәрне тирәнәйтү, анализлау, башлангыч күнекмәләр булдыру һәм аларны гамәли яктан тормышта дөрес кулланырга өйрәтү.

- Матур әдәбият әсәрләрен анализлау; тел бизәкләү, сурәтләү чараларын кулланып, төрле жанрда иҗат итү; алынган тема буенча телдән чыгыш ясый белү, язу күнекмәләрен булдыру.

**Программаның тәрбияви бурычы:**

- Үз милләтең белән горурлану, татар теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү.
- Төрле милләт вәкилләре арасында дуслык хисе тәрбияләү.
- Үз-үзеңне тоту һәм сөйләм культурасы тәрбияләү.
- Туган телен, матбугатын, мәдәниятен белгән камил шәхес тәрбияләү.

**Түгәрәк эшчәнлеге түбәндәге принципларга нигезләнә:**

- кызыксындыручанлык;
- фәннилек;
- аңлаешлылык;
- күрсәтмәлелек;
- теориянең практика белән тыгыз бәйләнеше;
- аңлы һәм актив эшчәнлек;
- һәр укучыга шәхси якын килү.

"Илһам" әдәби-иҗат берләшмәсе эшчәнлеге һәр укучының яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләү өчен, зур мөмкинлекләр тудыра.

Дәресләр структур яктан мәктәптә үткәрелүче традицион формадагы дәресләргә охшаган: оештыру, актуальләштерү, яңа материалны аңлату, ныгыту, йомгаклау. Дәресләрдә ныгытуга, ягъни гамәли эшкә, күнекмәләр бирүгә вакытның күпчелек өлеше сарыф ителә, кайбер дәресләр тулысы белән практик эшкә багышлана.

**Түгәрәк занятиеләрен** лекция, практикум, проект эше яклау, очрашу-әңгәмә, экскурсия, кичә һ.б. **формаларда** үткәрү күздә тотыла.

Программа айга 2 елга исәпләнгән.

Түгәрәктә 4Б һәм 6Б сыйныф укучылары шөгыльләнәчәк.

***Һәр занятие (шөгыль) өч өлештән тора: теория өлеше, практик өлеш һәм уен.***

*Төп метод һәм технологияләр:*

- ✓ үстерелешле укыту технологиясе;
- ✓ хезмәттәшлектә укыту технологиясе;

- ✓ коммуникатив технология;
- ✓ индивидуаль якын килү технологиясе.

***Планлаштырылган нәтиҗәләр***

- **<u>Шәхси-үзгәреш нәтиҗәләре:</u>**

- ✓ гомуми кулланыш нормалары һәм кыйммәтләре күзлегеннән кешеләрнең эш-гамәлләрен, тормыш ситуацияләрен бәяләү;
- ✓ текстны "эмоциональ кичерү", үз фикереңне белдерү;
- ✓ башка кешеләрнең хисләрен аңлау, кешенең хәленә керү, аңа теләктәшлек белдерү;
- ✓ Укылган әсәр геройларына карата үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү.

- **<u>Предметара нәтиҗәләр:</u>**

***Шәхси универсаль уку гамәлләре***

1. Түбәндәге кыйммәтләрне аңлый һәм бәяли белү: яхшылык, түземлелек, табигать, туган ил, гаилә һ.б. Үз гаиләңә, туганнарыңа, ата-анаңа хөрмәт.
2. Укуга карата кызыксыну формалаштыру.
3. Гомумкешелек нормалары күзлегеннән чыгып, тормыш ситуацияләрен, геройларның үз-үзләрен тотышларын бәяләү.

***Регулятив универсаль уку гамәлләре:***

1. Укытучы җитәкчелегендә эш урынын әзерләү, оешытру.
2. Укытучы җитәкчелегендә дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү максатын билгеләү.

***Танып-белү универсаль уку гамәлләре:***

1. Китап, вакытлы матбугат белән эшләү.
2. Төрле чыганаклардан тиешле мәгълүматны табу.
3. Әдәби әсәрләрдәге, халык авыз иҗаты үрнәкләрендәге геройларны, аларның гамәлләрен чагыштыру, уртак һәм аермалы якларын табу.
4. Укылган яки тыңланган текстның тел үзенчәлекләрен анализлау, сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйләү.

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:***

1. Дәрестән тыш эшчәнлектә һәм тормыш ситуацияләрендә диалогта катнашу.
2. Иҗади биремнәргә, сорауларга җавап бирү.
3. Сөйләм этикеты нормаларын үтәү.
4. Башкаларның сөйләмен тыңлап аңлау.
5. Парлап һәм төркемнәрдә иҗади эшләү.

**<u>Предмет нәтиҗәләре:</u>**

1. Укылган текстны ишетеп аңлау.
2. Балалар матбугаты белән даими танышу, төрле жанрда иҗат итү.
3. Татар әдәбияты тарихы буенча гомуми күзаллау булдыру.

“Илһам” әдәби-иҗат берләшмәсенә йөрүче укучыларның төрле дәрәҗәдәге бәйгеләрдә, фән олимпиадаларында, фәнни-гамәли конференцияләрдә актив катнашулары, газета-журналларга даими язышулары, әдәбият-сәнгать әһелләре белән очрашулары планлаштырыла.

***Төркемнәрдәге укучылар саны:***

1 нче уку елы – 30 бала

2 нче уку елы – 30 бала

***Бер елга сәгатьләр бүленеше:***

***Ике елга барлык сәгатьләр саны: 288 сәгать***

1 нче уку елы – 144 сәг.

**2** нче уку елы – 144 сәг.

## МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

“Илһам” әдәби-иҗат берләшмәсе дип аталган бу программада һәр бүлекне өйрәнгәннән соң рольле уеннар, иҗади эшләр һәм телдән хәбәрләр формасында контроль эшләр һәм зачетлар үткәрү планлаштырыла.

Уку-укыту материалының тупланышы аны эзлекле өйрәнү һәм вариатив куллану мөмкинлеген тәэмин итә. Һәм моны укучыларның әзерлек дәрәҗәсен, аларның яшь үзенчәлекләрен, региональ һәм милли үзгәлекләрне исәпкә алып, педагог үзе эшли.

Әлеге программаның мөһим компоненты булып милли-төбәк компоненты тора. Берләшмә утырышларына үз шәһәрең, әти-әнисенең туган ягы турында да культурологик материал кертү мөһим; шулай ук балаларда гаиләдәге гореф-гадәтләр, мәшһүр якташлар, туган төбәкнең мәдәни мирасына, татар теле кабинетында оештырылачак балалар язучысы Шәүкәт Галиев музей почмагына сакчыл караш тәрбияләргә дә өйрәтергә кирәк.

Иҗади эшчәнлеккә тарту укытучыдан бай иҗади лаборатория, күптөрле дидактик материал таләп итә. Балалар матбугатының тупланмасы, электрон вариантын куллану укучыларны пассив тыңлаучылар гына түгел, ә актив иҗатчылар итеп тәрбияләүгә ярдәм итә.

Материалың үзләштерү дәрәҗәсенең төп күрсәткечләре тупланган белемнәр генә түгел, укучыларның иҗади фикерләве, башкаларның иҗатына дөрес итеп бәя бирүләре, үз карашын нигезләп аңлата белүләре, аудитория каршында яклый алулары, булган белемнәрен гамәлдә куллана белүләреннән гыйбарәт. Укучыларның белем дәрәҗәсен ачыклау өчен, дискуссия, тикшеренү проектлары, иҗади эшләр конкурслары кебек чаралар да оештырырга мөмкин.

Материалын үзләштергәннән соң, йомгаклау дәресе булырга тиеш. Һәр темада дәресләр саны якынча бирелгән һәм, балаларның әзерлекләре дәрәҗәсен исәпкә алып, үзгәртелергә дә мөмкин.

## Программа буенча буенча белем бирү нәтиҗәлелеген тикшерү

Программа буенча белем бирү нәтиҗәлелеген тикшерү берничә этапта башкарыла: гадәти, яртыеллык, йомгаклау.

Гадәти (агымдагы) контроль берләшмә утырышларында һәр укучының эшчәнлеген, иҗади үсешен күзәтү, юнәлеш бирү, аның нәтиҗәләрен анализлау формасында уздырыла.

Яртыеллык контроль билгеле бер темаларны узгач, тестлар формасында уздырыла.

Йомгаклау тикшерүе һәр уку елы азагында иҗади остаханә, әдәби кичә, шигъри сабантуй, кызыклы очрашулар клубы һ.б. формаларда берләшмәнең ачык утырышы итеп уздырыла.

***Белем бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре*** : укучыларның туган телдә камил сөйләшүе, татар әдәбияты үрнәкләрен, иҗади осталык серләрен белүе, иҗат итүгә омтылыш уяну.

***Укучыларның белем-күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәләре өч төрдә бәяләнә:***

- югары
- уртача
- түбән

**Бу программаның үзенчәлеге шунда** – ул әзерлек дәрәҗәләре, белемнәре, мөмкинлекләре төрле булган балаларның мәнфәгатьләрен истә тотып төзелгән.

Программаны төзегәндә төрле дәрәҗәдәге критерийләр

- төрле катлаулылыкта булган укыту материалын эченә алган үз матрицасы бар;
- төрле катлаулылыкта булган укыту материалы методик яктан каралган;